СОВЕТ ОКТЯБРЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

27.07.2026 пос. Октябрьский 11-56

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге территориясендә гражданнардан сораштыру билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы, «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге территориясендә гражданнардан сорашып белешүне билгеләү һәм үткәрү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Советының 26.05.2021 ел №9-52 карары белән, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге территориясендә, «Югары Ослан муниципаль районының Үзәкләштерелгән клуб системасы» МБУнең 5 нче филиалы Матюшино авыл клубын бетерү мәсьәләсе буенча халык фикерен ачыклау максатында, исемле тавыш бирү рәвешендә гражданнардан сораштыру үткәрүне билгеләргә.
2. Билгеләргә:

- сораштыруны үткәрү датасы һәм вакыты - 07.08.2026 ел 8.00 дән 20.00 гә кадәр;

- сораштыру үткәрү урыны - Октябрьский авылы мәдәният йорты бинасы, адресы: Татарстан Республикасы, Югары Ослан районы, Октябрьский бистәсе, Үзәк урам, 7 йорт, Матюшино, Яңа Болгар, Ключищи авылларында - халык теркәлгән урынны әйләнеп чыгу.

3. Сораштыру исемлекләре буенча исемләп тавыш бирү үткәрергә
4. Гражданнардан сораштыру үткәргәндә сораштыру исемлегенә кертү өчен түбәндәге сорауның формулировкасын расларга: «Югары Ослан муниципаль районының Үзәкләштерелгән клуб системасы» МБУнең 5 нче филиалы Матюшино авыл клубын бетерүгә ризамы?"
5. Сораштыру үткәрү буенча комиссия төзергә һәм аның составын расларга (1 нче кушымта).

6. Сораштыру исемлегенең формасын һәм текстын расларга (2 нче кушымта).

7. Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлегендә 320 кешедән торган сораштыруда катнашучыларның минималь санын билгеләргә.

8. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтына, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына урнаштырырга.

Совет рәисе урынбасары,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районының
Октябрьский авыл җирлеге башлыгы урынбасары Р.Ф. Сибгатуллин

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл җирлеге
Советының 27.07.2026 ел, №11-56
карарына

1 нче кушымта

Гражданнардан сораштыру үткәрү

КОМИССИЯСЕ СОСТАВЫ

1. Азизов Шамиль Рамисович - Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге башлыгы.

2. Янгуразова Альфира Рашитовна - Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Башкарма комитеты секретаре.

3. Сафиуллина Раушания Рафкатовна - Яңа Болгар авылында яшәүче

4. Гадельшин Ильгизар Анварович - 7 нче Матюшино сайлау округы буенча Октябрьский авыл җирлеге Советы депутаты.

5. Гузельбаев Шамиль Халилович -5 нче Яңа Болгар сайлау округы буенча Октябрьский авыл җирлеге Советы депутаты

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл җирлеге
Советының 27.07.2026 ел, №11-56
карарына

1 нче кушымта

СОРАШТЫРУ ИСЕМЛЕГЕ

Сораштыру үткәреләә торган сорауны формулировкалау: «Югары Ослан муниципаль районының Үзәкләштерелгән клуб системасы» МБУнең 5 нче филиалы Матюшино авыл клубын бетерүгә ризамы?"

| Фамилия, исеме, атасы исеме | Туган көне, ае һәм елы | Яшәү урынының адресы | Дата | Тавыш бирү тамгасы | | Имза |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | РИЗА | КАРШЫ | |
| | | | | ☐ | ☐ | |
| | | | | ☐ | ☐ | |
| | | | | ☐ | ☐ | |
| | | | | ☐ | ☐ | |
| | | | | ☐ | ☐ | |

Комиссия рәисе________________________________________ ____________
(имза) (имзаның расшифровкасы) (дата)

Комиссия секретаре ______________ ________________ ____________
(имза) (имзаның расшифровкасы) (дата)